ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.11.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2929**

2022 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансны кайнар ризык белән туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елның 06 сентябрендәге Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача бәясен раслау турында» 826 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 07 сентябрендәге «2022 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 842 номерлы карарына туры китереп, Россия Федерациясенең 2015 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслылык һәм мохтаҗлык критерийларын куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезенд һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 14 февралендәге «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 181-ФЗ номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елның 12 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларга, һәр уку көненә 55 сум 55 тиен күләмендә бушлай кайнар ризык белән тәэмин итүне оештырырга.
2. 2022 елның 12 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен, Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү өчен,көн саен 8 сум 30 тиен күләмендә билгеләргә.
3. 2022 елның 12 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен Зеленодольск муниципаль районы

гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче һәр укучыга көн саен 63 сум 74 тиен күләмендә түбәндәге категорияләргә билгеләргә:

- үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләдәге укучыларга;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен «Норлат балалар йорты» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләргә.

4. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку чорында кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны, 2022 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә, гамәлгә ашырырга.

5. Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (ЕГИСО) операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасына (ЕГИСО) йөкләү өчен, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин